| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**19.12.2016** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 159** |

Зеленодольск муниципаль районы Советы “2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән расланган “Татарстан Республикасы “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертү турында”гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү карар проекты турында

Зеленодольск муниципаль районы Советы законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясе рәисе Г.Т. Савельевның 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының карары белән расланган «Татарстан Республикасы “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы Зеленодольск муниципаль районы Советы карар проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында карар проекты турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставының 15, 99-101 статьялары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районында ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә белән, Зеленодольск муниципаль районы **карар кылды:**

1. “2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән расланган «Татарстан Республикасы “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проектын хупларга һәм халык алдында тыңлауларга чыгарырга (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә.

3. Ачык тыңлаулар үткәрү инициаторы булып Зеленодольск муниципаль районы Советы тора.

4. Билгеләргә:

4.1. ачык тыңлауларны үткәрү датасы һәм вакыты – 2017 елның 26 гыйнвары, 16.00 сәгать.

4.2. ачык тыңлаулар үткәрү вакыты-1 көн;

4.3. ачык тыңлаулар үткәрү урыны – Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 46 йорт, “А. М. Горький исемендәге мәдәният, сәнгать һәм халык иҗаты үзәге”.

5. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына:

5.1. әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән гамәлдәге законнар, Зеленодольск муниципаль районының норматив хокукый актлары нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән вакытка Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

5.2.ачык тыңлаулар тәмамлангач, тыңлау нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм 2017 елның 03 февраленә кадәр халыкка мәгълүмат җиткерүне тәэмин итәргә.

6. “2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән расланган «Татарстан Республикасы “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә фикер алышуда катнашу тәртибен расларга.

7. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның фикер алышуда катнашуы әлеге карарның 6 пунктында күрсәтелгән тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

8. 2016 елның 27 декабренә кадәр әлеге карарны һәм әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән карар проектын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы
Советы 2016 елның 19 декабрендәге
159 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары проекты**

«___»__________ 2016 ел №_____

2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән расланган Татарстан Республикасы "Зеленодольск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законы, 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында" Федераль закон, 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законы, 2016 елның 29 сентябрендәге 75-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы “Зеленодольск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставының 15, 99-101 статьялары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1.2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына (Зеленодольск муниципаль район Советының 2006 елның 31 октябрендәге 96 номерлы, 2007 елның 9 июлендәге 190 номерлы, 2008 елның 10 июнендәге 313 номерлы, 2008 елның 20 октябрендәге 378 номерлы, 2010 елның 16 июнендәге 524 номерлы, 2012 елның 15 мартындагы 134 номерлы, 2012 елның 29 декабрендәге 223 номерлы, 2014 елның 21 февралендәге 361 номерлы, 2015

елның 5 мартындагы 492 номерлы, 2015 елның 28 августындагы 561 номерлы, 2016 елның 15 февралендәге 61 номерлы, 2016 елның 27 июнендәге 99 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 7.1 статьяда.:

1.1)7.1 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 11 пункт өстәргә:

«11) 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законда каралган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру.»;

2) 39 статьяда.:

2.1) 39 статьяның 17 пунктын 18 пункт дип санарга, 17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17) муниципаль-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру турында муниципаль-хосусый партнерлык өлкәсендә карарлар кабул итә, әгәр гавами партнер булып муниципаль берәмлек торса яисә муниципаль берәмлек катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырыла икән (Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырыла торган очраклардан тыш), шулай ук 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законда каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актлары башка федераль законнар, Зеленодольск муниципаль районының норматив хокукый актлары белән;

17.1) 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә дәүләт-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 18 статьясындагы 2 өлешендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле җирле үзидарә органы билгели";

17.2) 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә дәүләт - хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның 9 статьясындагы 2-5 өлешләре нигезендә проектның нәтиҗәлелеген бәяләү уздыру һәм аның чагыштырма өстенлеген билгеләү өчен муниципаль-хосусый партнерлык проектын Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органына җибәрә;

3) в статье 44:

3.1) 44 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктын 10 пункт дип санарга, 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә:

- хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә муниципаль хокукый актлар кабул итә;

- хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә координация органнары булдыра;

- хокук бозулар кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар күрә;

-муниципаль берәмлек территориясендә хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итә;

- 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 1, 7-10 пунктларында каралган хокук бозуларны профилактикалауны гамәлгә ашыра;

- хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә башка хокукларны гамәлгә ашыра;”;

4) 44.2. статьяда:

4.1) 44.2 статьяның 1 өлешендәге 9 пунктын 10 пункт дип санарга, 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“9) хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә:

- хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә муниципаль хокукый актлар кабул итәләр;

- хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә координация органнары булдыралар;

- хокук бозулар кылуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар күреләә;

-муниципаль берәмлек территориясендә хокук бозуларны профилактикалауда катнашучы затларның үзара хезмәттәшлеген тәэмин итәләр;

- 2016 елның 23 июнендәге 182-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 1, 7-10 пунктларында каралган хокук бозуларны профилактикалауны гамәлгә ашыралар;

- хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә башка хокукларны гамәлгә ашыралар;”;

2. Әлеге карарны закон белән билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәлүенә җибәрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше, Татарстан Республикасы “Зеленодольск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставының 101 статьясындагы 2,3 өлешләре нигезендә үз көченә керә дип билгеләргә

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны “Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль районы
Советы 2016 елның 19 декабрендәге
159 номерлы карарына
2 нче кушымта

Зеленодольск муниципаль районы Советы " 2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән расланган "Татарстан Республикасы "Зеленодольск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертү турында"гы карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның фикер алышуда катнашу

ТӘРТИБЕ

1. Зеленодольск муниципаль районы Советының "2005 елның 14 декабрендәге 18 номерлы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән расланган Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында"гы карары проектына тәкъдимнәр Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына түбәндәге адрес буенча кертелә: Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а йорт, 306 каб., кушымта итеп бирелә торган үрнәк нигезендә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә язма рәвештә кертелә:

| № п/п | Пункт, пунктча | Карар проекты тексты | Төзәтмә ләр тексты | Төзәтмәне исәпкә алып, проект тексты | Төзәтмә авторы (Ф. И. О., адрес, эш, уку урыны) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр, карар кабул ителгән көннән алып, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә кабул ителә.

2. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар, чыгыш ясау хокукы белән, Зеленодольск шәһәре, Ленин урамы, 41а адресы буенча, шәхсән бирелә.

Гаризалар эш көннәрендә иртәнге сәгать 8.00 кичке сәгать 17.00 кадәр ачык тыңлаулар үткәрү датасына кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Зеленодольск муниципаль районы Советы аппараты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына Зеленодольск муниципаль районы Советының 2006 елның 15 декабрендә кабул ителгән 131 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә карап тикшерү өчен тапшырыла.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**